| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ МУРТЫШ- ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МОРТЫШТАМАК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

17.12.2025 №9

**«Җир салымы турында» 2020 елның 23 мартындагы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Мортыштамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Мортыштамак авыл җирлеге советы карар кылды:

1.«Җир салымы турында» 2020 елның 23 мартындагы 3 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге советы карарына (Советның 11.11.2020 елның 11 номерлы, 27.02.2023 елның 2 номерлы, 02.11.2023 елның 17 номерлы, 28.02.2025 елның 1 номерлы, 20.10.2025 елның 5 номерлы, 25.11.2025 елның 6 номерлы кертелгән карарлары белән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4.2.2 пунктчасы өстәргә:

«4.2.2. Күпфатирлы йортлар астында урнашкан җир кишәрлекләре өчен торак милекчеләре ширкәтләре тарафыннан.».

2.Мортыштамак авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 23 мартындагы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 25 ноябрендәге 6 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 01.01.2025 елда барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге
Советы И.И.Хафизов